**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

**30.11.2022ел** **№ 03-20**

**2022-2023 елларда кышкы чорда**
**вакытлыча кар өю урыннарын билгеләү турында**

Интенсив кар яву чорында юлларны һәм урамнарны вакытында чистартуны тәэмин итү, Түбән Табын авыл җирлегендә 2022-2023 елларның кышкы чорында территорияне җыештыруны тәртипкә салу һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә карны вакытлыча өю урыннарын билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, Мөслим районы прокурорының 2022 елның 21 ноябрендәге 02-08-02-2022 номерлы күрсәтмәләрен үтәү йөзеннән, Түбән Табын авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.2022-2023 елларның кышкы чорында карны вакытлыча тоту өчен ачык мәйданчыклар сыйфатында түбәндәге территорияне билгеләргә:

- Югары Табын авылы – кад.№ 16:29:10701:71
- Түбән Табын, Тегермәнлек авыллары – кад.№ 16:29:10802:10
- Тамьян авылы – кад. № 16:29:10802:63
- Тугаш авылы – кад. № 16:29:10801:94
- Кызыл Яр торак пункты – кад. № 16:29:10801:83

2.Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә һәм хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

*ТР Мөслим муниципаль районының*
*Түбән Табын авыл җирлеге*
*башкарма комитеты җитәкчесе* *Р.Ш. Кыяметдинов*